**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«8» октябрь 2025ел № 141

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 декабрендәге 292 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, сату сәүдәләр үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган, җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында» федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 декабрендәге 292 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, сату сәүдәләр үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган, җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләү тәртибен раслау турында» карарына (26.08.2022 № 163 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибендә:

2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтенә, мондый ширкәт әгъзасына бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән бакча җир кишәрлеге яисә яшелчә җир кишәрлеге;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин